**МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ОТДЕЛ ОБРАЗОВАНИЯ» АТНИНСКОГО РАЙОННОГО ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫНЫҢ "МӘГАРИФ БҮЛЕГЕ" МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА ОЕШМАСЫ**

422750, с. Большая Атня, ул. Октябрьская, 9 Тел.: (843)-69-2–10–60. тел./факс: (843)-69- 2–10–46 E-mail: roo_atnia@mail.ru

№ 170-о/д от 04.12.2020г.

**Приказ**

**О проведении конкурса сочинений «И туган тел»**

В целях сохранения и развития национальной культуры и языка ПРИКАЗЫВАЮ:

1. Провести с 07 по 21 декабря 2020 года среди образовательных учреждений конкурс сочинений «И туган тел».

2. Утвердить положение районного конкурса (Приложение 1).

3. Ответственным за проведение назначить методиста МКУ «Отдел образования» Нигматову Лейсан Ильфатовну.

**Начальник** **Л.Т.Гарипов**

Приложение 1
к приказу МКУ "Отдел образования"
Атнинского районного исполнительного комитета
№ 170-о/д от 04.12.2020г.

**Районкүләм «И туган тел!» бәйгесе**
**НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

## 1. Гомуми нигезләмә

1.1. «И туган тел» бәйгесе (алга таба - Бәйге) "ТАТМЕДИА" АҖ "Әтнә таңы" газетасы редакциясе белән берлектә Әтнә муниципаль районы башкарма комитетының "Мәгариф бүлеге" муниципаль казна оешмасы тарафыннан уткәрелә.

## 2. Бәйгенен максатлары һәм бурычлары

2.1. Бәйге уздыруның төп максатлары:
- татар телен, әдәбиятын, мәдәниятен саклау һәм үстерү;
- укучыларда әдәбияткә, сәнгатькә кызыксыну уяту;
- әдәби иҗатка сәләте булган яшьләрне ачыклау, барлау, осталыкларын үстерергә ярдәм итү.

## 3. Бәйгене оештыру комитеты

3.1. Бәйгене үткәрү өчен "ТАТМЕДИА" АҖ "Әтнә таңы" газетасы редакциясе һәм Әтнә муниципаль районы башкарма комитетының "Мәгариф бүлеге" муниципаль казна вәкилләреннән торган оештыру комитеты төзелә.

## 4. Катнашучыларга һәм иҗади эшләргэ таләпләр

4.1. Бәйгедә татар телендә иҗат итүче мәктәп укучылары катнаша ала.

4.2. Бәйгегә җибәрелгән эшләр өч яшь категориясенә бүленеп карала:

*1) 5-7 сыйныфлар*;
*2) 8-9 сыйныфлар*;
*3)10-11 сыйныфлар.*

Бәйгедә катнашучы татар телендә язылган инша тәкъдим итә. Укучы үзенең иншасында туган телгә булган мөнәсәбәтен, карашын, уйларын ачып күрсәтергә, татар теленең бүгенгесе, киләчәге, туган телебез язмышы, аны саклау мәсьәләләре турында үз фикерен белдерергә тиеш.

4.3. Инша матбугат битләрендә һәм башка бәйгеләрдә кулланылмаган булуы сорала.

4.4. Бәйге эшләренең бизәлешенә таләпләр: WORD документы, A4 форматы, Times New Roman шрифты 14, 1,5 интервал, читләрдән 2 см. Эшләр электрон форматта гына җибәрелә.

4.5. Титул битендә мәктәпнең тулы исеме, иншаның исеме, башкаручы (сыйныф) һәм җитәкченең тулы исемнәре булырга тиеш.

4.6. **Эшне укучының ФИО, класс, мәктәп исеме белән исемләргә.**

## 5. Бәйгене үткәрү тәртибе

5.1. Бәйгедә катнашучы үзе язган иншаны һәм үзе турындагы гаризаны (кушымта 1) оештыру комитетына nigmatova_89@mail.ru адресына 2020 елның 21 нче декаберенә кадәр

юллый.

5.2. Бәйге бер турда уздырыла:

Экспертлар төркеме барлык иншалар белән таныша һәм алар арасыннан иң яхшыларын сайлап ала.

5.3. Бәйге нәтижәләре, җиңүчеләр турында мәгълүмат Әтнә районының Мәгариф бүлеге сайтына һәм дә "Әтнә таңы" газетасында, сайтында урнаштырыла.

## 6. Жюри составы

1. Хөснетдинова Алсу Мисалим кызы – Әтнә районы башкарма комитетының "Мәгариф бүлеге"нең укыту эшләре буенча җитәкче урынбасары;
2. Гыйззатова Айсылу Рафиз кызы - Әтнә районы башкарма комитетының "Мәгариф бүлеге"нең тәрбия эшләре буенча җитәкче урынбасары;
3. Нигматова Ләйсән Илфат кызы - Әтнә районы башкарма комитетының "Мәгариф бүлеге"нең милли мәгариф өчен җаваплы методисты;
4. Мөхәмәдҗанова Гөлнар Равил кызы – "ТАТМЕДИА" АҖ "Әтнә таңы" газетасы редакциясе җитәкчесе;
5. Филатова Фәридә Фаязовна – "ТАТМЕДИА" АҖ "Әтнә таңы" газетасы редакциясе корреспонденты.

## 7. Бәйгене үткәрү тәртибе

Һәр яшь категориясендә призлы урыннар алган катнашучылар"ТАТМЕДИА" АҖ "Әтнә таңы" газетасы редакциясе һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы башкарма комитетының "Мәгариф бүлеге" муниципаль казна оешмасы грамоталары һәм истәлекле бүләкләре белән бүләкләнә.

Кушымта 1

**"И туган тел" бәйгесендә катнашу өчен гариза**

| № п.п. | Фамилиясе, исеме, этисенең исеме, | Район, мәктәп, класс, яшь | Элемтә өчен телефон (мәктәп, өй яки сот. телефон номеры) | Җитәкченең фамилиясе, исеме, этисенең исеме |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |